# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«26» сентябрь 2022 ел № 405

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильичевский авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 27 окябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Ильичевский авылында Ильичевская урамы буенча 1 йорт янында Ильичевский авылының Ильичевская ур., Прибрежная ур., Олимпийская ур., Первомайский кардон буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Ильичевский авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Ильичевский авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов